Боерык проекты

ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 175

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«22» октябрь 2021ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2020 елның 10 февралендәге 29 номерлы боерыгы белән расланган Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын норматив таләпләрдә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган техник торышта карап тоту, йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларының яисә аларның состав өлешләренең техник торышын билгеләү, әлеге җиһазда төзексез урыннарны эзләү һәм ачыклау, шулай ук алга таба аннан файдалану мөмкинлеген билгеләү эшләрен башкару һәм хезмәтләр күрсәтү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында белдерүләр кабул итү һәм исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе норматив хокукый актын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2020 елның 10 февралендәге 29 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2020 елның 30 июлендәге 148 номерлы, 2020 елның 28 октябрендәге 191 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын норматив таләпләрдә белдерелә торган таләпләргә туры килә торган техник торышта карап тоту, йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ

җиһазларының яисә аларның состав өлешләренең техник торышын билгеләү, әлеге җиһазда төзексез урыннарны эзләү һәм ачыклау, шулай ук алга таба аннан файдалану мөмкинлеген билгеләү эшләрен башкару һәм хезмәтләр күрсәтү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында белдерүләр кабул итү һәм исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Н.Н. Воронская) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2021 елның 22 октябрендәге 175 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2020 елның 10 февралендәге 29 номерлы боерыгы белән расланган Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын норматив таләпләрдә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган техник торышта карап тоту, йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларының яисә аларның состав өлешләренең техник торышын билгеләү, әлеге җиһазда төзексез урыннарны эзләү һәм ачыклау, шулай ук алга таба аннан файдалану мөмкинлеген билгеләү эшләрен башкару һәм хезмәтләр күрсәтү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында белдерүләр кабул итү һәм исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәккә (алга таба – КФҮ), КФҮнең читтәге эш урыннарына (шәхсән яисә телефон буенча) мөрәҗәгать иткәндә.»;

1.7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР Дәүләт торак инспекциясенең урнашкан урыны, белешмә телефоны, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарының урнашкан урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырыла.»;

1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.9. Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

аутентификация – аутентификация уздыручыда зат турында булган белешмәләрне чагыштыру һәм аутентификация процедурасы кысаларында аутентификацияли торган билгене (билгеләрне) куллану юлы белән затның идентификаторга (идентификаторларга) ия булуының хокуклылыгын билгеләү юлы белән идентификаторның (идентификаторларның) аңа каравы буенча затны тикшерүгә кагылышлы чаралар җыелмасы, шуның нәтиҗәсендә зат билгеләнгән дип танылa;

идентификацияләү – зат турында мәгълүматлар билгеләү һәм аларны тикшерү һәм әлеге мәгълүматларны затны билгеләү өчен кирәкле булган мондый зат турындагы белешмәләрнең уникаль билгеләнеше (уникаль билгеләнешләре) белән чагыштыру буенча федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла торган чаралар җыелмасы;

Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба – ИАБС) – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәк – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торган), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма.

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны (алга таба – КФҮ читтәге эш урыны) – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

КФҮ АМС – күпфункцияле үзәкләр эшчәнлегенә ярдәм итүнең автоматик мәгълүмат системасы;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба гариза) 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 3 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла. Гаризаларның тәкъдим ителә торган формалары әлеге Регламентка карата 1, 3 нче кушымталарда китерелгән.».

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты.

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын норматив таләпләрдә белдерелә торган таләпләргә туры килә торган техник торышта карап тоту, йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларының яисә аларның состав өлешләренең техник торышын билгеләү, әлеге җиһазда төзексез урыннарны эзләү һәм билгеләү, шулай ук алга таба аннан файдалану мөмкинлеген билгеләү буенча эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында белдерүләр (алга таба – белдерү) кабул итү һәм исәпкә алу;

2.2. Башкарма хакимият органы исеме.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – Дәүләт торак инспекциясе).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау:

а) ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан белдерүләр теркәү һәм гариза бирүчегә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән белдерүне тапшыру (җибәрү);

б) Белдерүләр реестрына белешмәләр кертү юлы белән, белдерүләр исәбен алып бару;

в) гариза бирүчедән тиешле үзгәрешләр турында мәгълүмат алынган очракта, ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Белдерүләр реестрына үзгәрешләр кертү;

г) Белдерүләр реестрындагы мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында урнаштыру.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан белдерүне теркәү һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән белдерүне гариза бирүчегә тапшыру (җибәрү) – белдерү ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көнгә туры килә торган көн дәвамында.

Белдерүләр реестрында булган мәгълүматларга үзгәрешләр кертү (юридик зат урнашкан урынның һәм (яки) фактта ул эшчәнлек башкара торган урынның үзгәрүе, шәхси эшкуарның яшәгән урыны һәм (яки) эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыра торган урынның үзгәрүе, юридик затны үзгәртеп кору) – тиешле документлар ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көннән башлап биш эш көне.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, Белдерүләр реестрына үзгәрешләр кертелүе хакында мөрәҗәгать итүчегә хат җибәрү (почта аша яки

электрон адреска) – Белдерүләр реестрында булган белешмәләргә үзгәрешләр кертелгәннән соң киләсе эш көнендә.

Белдерүләр реестрындагы мәгълүматларны ТР Дәүләт торак инспекциясе рәсми сайтында урнаштыру – белдерү теркәлгән көннән башлап 10 календарь көне.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе.

Белдерүне теркәү һәм аны Белдерүләр реестрына кертү өчен:

ике нөсхәдә белдерү турыдан-туры ТР ДТИ яисә берәр нөсхәдә – КФҮ, КФҮ читтәге эш урыны аша әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына ярашлы форма буенча.

Юридик зат һәм шәхси эшкуарга кагылышлы үзгәрешләр турындагы мәгълүматларны Белдерүләр реестрына кертү өчен:

тиешле үзгәрешләр кертү фактын раслаучы документларның күчермәләрен теркәп, ирекле формада үзгәрешләр кертү турында гариза.

Документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);

кулга тапшыру турында белдереп, теркәлгән документлар исемлеге белән заказлы почта юлламасы итеп.

Документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы, КФҮ аша, ТР ДТИ рәсми сайтында (https://gji.tatarstan.ru) Интернет-кабул итү системасы аша да электрон формада тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

КФҮдә турыдан-туры мөрәҗәгать итүче кәгазьдә бер нөсхәдә белдерү тапшыра. Мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүченең вәкиле тарафыннан КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, аңа Россия Федерациясе гражданины паспортын һәм (яисә) мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклаучы башка документны күрсәтергә кирәк.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма. Дәүләт хезмәте

күрсәтү өчен ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында документлар алу таләп ителми.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

Документлар кабул итүдән баш тарту нигезләре:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентка 1 нче кушымтада каралган форманы бозып төзелгән белдерүне тапшыру;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан үзгәрешләр кертү фактын раслаучы документлар кушымтасыннан башка гариза бирү.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр.

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп.

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры.

Мөрәҗәгать итүчене кабул итүне (аңа хезмәт күрсәтелүне) көтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да.

Белдерү яки гариза кергән көнне.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән белдерү яки гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

Белдерүне турыдан-туры КФУ тапшырганда, аны бирү көне булып белдерүне теркәү көне санала.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт

хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү ТР Дәүләт торак инспекциясенең янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционерлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән бинасында һәм бүлмәләрендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, ТР Дәүләт торак инспекциясе биналарыннан, бүлмәләреннән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасына һәм бүлмәләренә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

ТР Дәүләт торак инспекциясе территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасында һәм бүлмәләрендә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасыннан, бүлмәләреннән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасына һәм бүлмәләренә озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган

каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15.1 статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы.

Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында ТР Дәүләт торак инспекциясенең мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы;

ТР ДТИ мәгълүмат ресурслары ярдәмендә электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итү;

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән характерлана:

документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләр аларны тапшырганда чиратлар;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозулар;

дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләре гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;

дәүләт хезмәтен күрсәткән граждан хезмәткәрләренең мөрәҗәгать итүчеләргә карата дорфа, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте

күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазифаи зат белән мөрәҗәгать итүче арасында бер мәртәбә хезмәттәшлек итү күздә тотыла. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәктә күрсәтелгән очракта, документларны кабул итү һәм бирү күпфункцияле үзәк белгече тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны һәм документларның гариза теркәлгән көннән башлап бер эш көне эчендә ТР ДТИ тапшырылуы тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ТР ДТИ һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибе ТР ДТИ һәм КФҮ арасында төзелә торган килешү белән җайга салына, ә КФҮнең мөрәҗәгать итүчеләр белән хезмәттәшлек итү тәртибе – КФҮ эше Регламенты белән. Дәүләт хезмәте экстриториаль принцип буенча комплекслы гариза составында күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан ТР Дәүләт торак инспекциясенең http://www.gji.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан алынырга мөмкин.

Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында консультация электрон формада ТР ДТИ рәсми сайтындагы (https://gji.tatarstan.ru) Интернет-кабул итү системасы аша, ТР ДТИ телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яисә телефон аша); ТР ДТИ язмача мөрәҗәгать итеп (электрон почта адресы: tatgi@tatar.ru); «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре (алга таба – «Интернет» челтәре) аша алынырга мөмкин.

Белдерү (гариза) белән документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.»

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә түбәндәге административ процедуралар башкарыла:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гариза бирүчеләрдән белдерүләр кабул итү;

3) белдерүләрне теркәү;

4) белдерүләрне исәпкә алу һәм Реестр алып бару;

5) мәгълүматларны ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында урнаштыру;

6) Реестрга үзгәрешләр кертү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирү (җибәрү);

8) техник хатаны төзәтү.

3.3. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып түбәндәгеләр тора:

- мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – күпфункцияле үзәк белгече;

- мөрәҗәгать итүче ТР ДТИ мөрәҗәгать иткән очракта – Бүлек белгече.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат сорап, күпфункцияле үзәккә шәхсән үзе һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле башка мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүчеләргә мәгълүмат бирү КФҮ тарафыннан үзара хезмәттәшлек турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашыра.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәкнең http://mfc16.tatarstan.ru/ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

3.2.3. Гариза бирүче ТР Дәүләт торак инспекциясенең дәүләт хезмәте күрсәтү

өчен җаваплы вазыйфаи затына (алга таба – вазыйфаи зат) шәхсән, телефон аша, язмача һәм (яки) Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы интернет-кабул итү системасы аша (https://gji.tatarstan.ru) электрон белдерү формасында яки вазыйфаи затка шәхсән мөрәҗәгать итү формасында дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Вазыйфаи зат гариза бирүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Белдерүләр кабул итү.

3.3.1. ТР Дәүләт торак инспекциясенә гариза бирүчеләрдән белдерүләр килү белдерүләрне кабул итү буенча административ гамәлләрне башлап җибәрү нигезе булып тора.

3.3.2. Гариза бирүче (аның вәкиле) шәхсән кәгазьдә яисә кулга тапшыру турында белдереп, теркәлгән документлар исемлеге белән почта аша заказлы юллама итеп җибәрә, яки гариза бирүченең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендәге белдерүне гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша да, ТР ДТИ рәсми сайтында (https://gji.tatarstan.ru) Интернет-кабул итү системасы аша электрон формада җибәрә.

3.3.3. Белдерүне ТР Дәүләт торак инспекциясенә турыдан-туры тапшырган очракта, аны теркәү көне дип белдерүне тапшыру көне санала. Белдерүне почта аша җибәргәндә, аны бирү көне итеп почта юлламасын җибәрү көне санала. Белдерүне электрон документ рәвешендә җибәргән очракта, аны тапшыру көне булып, ТР ДТИ электрон документ әйләнеше системасында бу документны теркәү көне санала.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән белдерү ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

3.3.4. Белдерүләр кабул итү һәм исәпкә алу функциясе ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы белән ТР Дәүләт торак инспекциясе вазыйфаи затына беркетелә.

3.3.5. Вазыйфаи зат:

белдерүне кабул итә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 16 июлендәге 584 номерлы карары белән расланган Эшкуарларның аерым төрләре тарафыннан эшчәнлек башлау турында белдерү тапшыру һәм әлеге белдерүләрне исәпкә алу кагыйдәләрендә (алга таба – Кагыйдәләр) билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве буенча белдерү формасын тикшерә;

документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавына карата белдерүне тикшерә.

3.3.6. Әлеге Регламентның 2.7 пунктының икенче абзацында каралган нигезләр булмаган очракта, вазыйфаи зат белдерүне теркәү турында гариза бирүче өчен хат әзерли һәм аны, карау өчен, торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлеге башлыгына җибәрә.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктының икенче абзацында каралган нигезләр булган очракта, вазыйфаи зат, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, гаризаны теркәмичә генә кире кайтара.

3.3.7. Вазыйфаи зат «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасы (алга таба – электрон документ әйләнеше) аша гариза бирүчегә дигән хатны электрон формада ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгына килештерү өчен җибәрә.

3.3.8. Административ процедураны үтәү вакыты – белдерү ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көн дәвамында.

3.3.9. Административ процедураның нәтиҗәсе – документларны кабул итү, хатны имза салу өчен ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгына җибәрү, ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан белдерүне теркәү процедурасына кучу яки документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү тапшыру (җибәрү).

3.3.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны күпфункцияле үзәк аша яки күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша кабул итү.

КФҮдә турыдан-туры мөрәҗәгать итүче кәгазьдә бер нөсхәдә белдерү тапшыра.

Белдерүне турыдан-туры КФҮ тапшырганда, аны бирү көне булып белдерүне теркәү көне санала.

Белдерү КФҮ тапшырылган очракта, КФҮ вазыйфаи заты белдерүнең электрон рәвешен формалаштыра, аны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып вәкаләтле органга җибәрә, белдерүдә кабул итү турында билге куя һәм мөрәҗәгать итүчегә кире кайтара.

3.3.11. Күпфункцияле үзәкнең белдерүләрне кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән белдерү.

3.4. Белдерүләрне теркәү.

3.4.1. Гариза бирүчедән килгән белдерүләрнең Кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен билгеләү ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан белдерүләр теркәү буенча административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.2. ТР Дәүләт торак инспекциясенең килгән белдерүләрне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты, Кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган

белдерү алынган көнне аны терки һәм ике нөсхәсендә аны теркәү датасын һәм теркәү номерын күрсәтә.

Белдерүнең бер нөсхәсе ТР Дәүләт торак инспекциясендә кала, икенчесе – белдерүне теркәү турындагы хат белән бергә, гариза бирүчегә аны теркәү көнендә тапшырыла (җибәрелә).

Административ процедураны үтәү вакыты бер эш көне тәшкил итә.

Гариза бирүчегә теркәлгән белдерүне һәм белдерүне теркәү турындагы хатны тапшыру (җибәрү)административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

Хат һәм теркәлгән белдерү гариза бирүчегә шәхсән тапшырыла яки, гариза бирүче турында номеры, датасы һәм белешмәләре күрсәтелеп, ТР Дәүләт торак инспекциясеннән чыга торган корреспонденцияләр журналында теркәлеп, почта аша җибәрелә.

Белдерү электрон документ рәвешендә тапшырылган очракта, килгән белдерүләрне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи зат аны теркәгән көнне белдерүне алу турында ТР Дәүләт торак инспекциясенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә раслама җибәрергә тиеш.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән белдерү.

3.5. Белдерүләрне исәпкә алу һәм Реестрны алып бару.

3.5.1. Белдерүләрне теркәү белдерүләрне исәпкә алу һәм Реестрны алып бару буенча административ процедурасын башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

3.5.2. ТР Дәүләт торак инспекциясенең килгән белдерүләрне исәпкә алу өчен җаваплы булган вазыйфаи заты белдерү алынган көнне Реестрга түбәндәге мәгълүматларны кертә:

- юридик затның тулы һәм кыскартылган, шул исәптән фирма атамасы (булган очракта), аның оешу-хокук формасы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме турында;

- юридик затның, шул исәптән аның филиалларының һәм вәкиллекләренең, билгеләнгән эшчәнлек төрен фактта гамәлгә ашыру урыннарының, шәхси эшкуар эшчәнлегенең билгеләнгән төрен фактта гамәлгә ашыру урыннарының почта адреслары турында;

- юридик затның төп дәүләт теркәү номеры яки шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу турындагы язуының төп дәүләт теркәү номеры турында;

- салым түләүченең идентификация номеры, юридик затны яки шәхси эшкуарны салым органында исәпкә кую датасы турында;

- белдерүдә аларны башлап җибәрү турында белдерелә торган эшчәнлек төре, эшчәнлек составында башкарыла торган эш төрләре (хезмәтләр) турында;

- белдерү килгән көн һәм аны теркәү номеры турында.

3.5.3. Реестр кәгазьдә һәм электрон чыганакларда да алып барыла. Реестрны кәгазь чыганакта алып бару өчен, ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендә белдерүләрне теркәү журналы рәсмиләштерелә.

3.5.4. Белдерүдәге мәгълүматларны Белдерүләр реестрына кертү административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

Административ процедураны үтәү вакыты бер эш көне тәшкил итә.

3.6. Мәгълүматларны ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында урнаштыру.

3.6.1. Белдерүләрне теркәү ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында мәгълүматларны урнаштыру буенча административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

ТР Дәүләт торак инспекциясенең вазыйфаи заты Белдерүләр реестрындагы мәгълүматларны ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында урнаштыра.

Административ процедураны үтәү вакыты белдерүне теркәгәннән соң 10 календарь көне тәшкил итә.

Мәгълүматларны ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында урнаштыру Административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.7. Белдерүләр реестрына үзгәрешләр кертү.

3.7.1. ТР Дәүләт торак инспекциясенә гариза бирүчеләрдән, тиешле үзгәрешләр кертелү фактын раслый торган документларның күчермәләрен теркәп, гаризалар килүе ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Белдерүләр реестрына үзгәрешләр кертү буенча административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

3.7.2. Вазыйфаи зат:

гаризаны һәм теркәлгән документларны кабул итә;

әлеге Регламентның 2.7 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

3.7.3. Әлеге Регламентның 2.7 пунктындагы өченче абзацында каралган нигезләр булмаган очракта, вазыйфаи зат гариза бирүчегә Белдерүләр реестрына үзгәрешләр кертү турында хат әзерли һәм аны, карау өчен, торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлеге башлыгына җибәрә.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктының өченче абзацында каралган нигезләр булган очракта, вазыйфаи зат, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

3.7.4. Вазыйфаи зат гариза бирүчегә дигән хатны, килештерү өчен, электрон рәвештә электрон документ әйләнеше системасы аша ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгына җибәрә.

3.7.5. Вазыйфаи зат Белдерүләр реестрына үзгәрешләр кертә.

3.7.6. Вазыйфаи зат Белдерүләр реестрында булган, үзгәртелгән мәгълүматларны ТР Дәүләт торак инспекциясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.

3.7.7. Әлеге Регламентның 3.7 пунктында каралган үзгәрешләр тиешле документлар ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көннән башлап биш эш көне эчендә вазыйфаи зат тарафыннан кертелә.

Документларны кабул итү, хатны имзалау өчен ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгына җибәрү, хатны гариза бирүчегә юллау, Белдерүләр реестрына үзгәрешләр кертү, Белдерүләр реестрында булган мәгълүматларны ТР Дәүләт торак инспекциясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру яки гариза бирүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында

белдерү тапшыру (җибәрү) административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирү (җибәрү).

3.8.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга хокуклы:

шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);

кулга тапшыру турында белдереп, теркәлгән документлар исемлеге белән заказлы почта юлламасы итеп;

электрон почта аша.

3.8.2. Вазыйфаи зат хатны һәм теркәлгән белдерүне мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшыра яки, номерын, датасын һәм мөрәҗәгать итүче турындагы белешмәләрне күрсәтеп, ТР Дәүләт торак инспекциясеннән җибәрелә торган корреспонденцияләр журналында теркәп, почта аша җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла – мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе шәхсән тапшырылган очракта, Белдерүләр реестрында булган белешмәләргә үзгәрешләр кертелгәннән соң икенче эш көнендә – дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе почта (электрон почта) буенча җибәрелгән очракта.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тора.

3.8.3. Мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, орган (оешма) тарафыннан җибәрелгән электрон документның эчтәлеген раслаучы документ формасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе КФҮ аша алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе КФҮ аша түбәндәге документларны күрсәткән мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) бирелә:

мөрәҗәгать итүченең яисә аның вәкиленең шәхесен таныклаучы документ;

мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү тора.

3.9. Техник хатаны төзәтү.

3.9.1. ТР Дәүләт торак инспекциясенә техник хатаны төзәтү турында гариза килү белдерүдәге техник хатаны төзәтү буенча административ процедураны башлап җибәрү нигезе булып тора.

3.9.2. Белдерүдә техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче ТР Дәүләт торак инспекциясенә әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына туры китерелгән форма буенча техник хатаны төзәтү турында гариза, шулай ук әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына туры китерелгән форма буенча ике нөсхәдә белдерү тапшыра.

3.9.3. Җаваплы башкаручы документларны карый һәм, нигез булган очракта, яңа белдерүне терки. Яңа белдерү Белдерүләр реестрында теркәлә.

3.9.4. Теркәлгән белдерү гариза бирүчегә (Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле затка)

кул куйдыртып тапшырыла яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрелә.

Техник хата җибәрелгән белдерү акт буенча юкка чыгарыла.

3.9.5. Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура белдерүдә язу, басма хатаны төзәтү турында гариза килгән датадан башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.9.6. Процедураның нәтиҗәсе: яңа белдерүне теркәү, теркәлгән яңа белдерүне гариза бирүчегә җибәрү яки тапшыру.

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

«5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр ТР Дәүләт торак инспекциясе, ТР Дәүләт торак инспекциясе вазыйфаи заты, граждан хезмәткәре, КФҮ карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә ТР Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесенә шикаять белдерергә хокуклы. ТР Дәүләт торак инспекциясенә алынган шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сәбәпле ТР Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

д) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торган очракта;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтыннан (https://gji.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. ТР Дәүләт торак инспекциясенә алынган шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. ТР ДТИ мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең яки хезмәткәренең исеме.

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы икенче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта гариза

бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында ТР Дәүләт торак инспекциясе, КФУ тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.».

Административ регламентка (белешмәлек) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын норматив таләпләрдә белдерелә торган таләпләргә туры килә торган техник торышта карап тоту, йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларының яисә аларның состав өлешләренең техник торышын билгеләү, әлеге җиһазда төзексез урыннарны эзләү һәм билгеләү, шулай ук алга таба аннан файдалану мөмкинлеген билгеләү буенча эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында белдерүләр кабул итү һәм исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

**ЮРИДИК ЗАТЛАР ҺӘМ ШӘХСИ ЭШКУАРЛАР ТАРАФЫННАН ЙОРТ ЭЧЕНДӘГЕ ҺӘМ (ЯКИ) ФАТИР ЭЧЕНДӘГЕ ГАЗ ҖИҺАЗЛАРЫН НОРМАТИВ ТАЛӘПЛӘРДӘ БЕЛДЕРЕЛӘ ТОРГАН ТАЛӘПЛӘРГӘ ТУРЫ КИЛӘ ТОРГАН ТЕХНИК ТОРЫШТА КАРАП ТОТУ, ЙОРТ ЭЧЕНДӘГЕ ҺӘМ (ЯКИ) ФАТИР ЭЧЕНДӘГЕ ГАЗ ҖИҺАЗЛАРЫНЫҢ ЯИСӘ АЛАРНЫҢ СОСТАВ ӨЛЕШЛӘРЕНЕҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫН БИЛГЕЛӘҮ, ӘЛЕГЕ ҖИҺАЗДА ТӨЗЕКСЕЗ УРЫННАРНЫ ЭЗЛӘҮ ҺӘМ БИЛГЕЛӘҮ, ШУЛАЙ УК АЛГА ТАБА АННАН ФАЙДАЛАНУ МӨМКИНЛЕГЕН БИЛГЕЛӘҮ БУЕНЧА ЭШЛӘР БАШКАРУ ҺӘМ ХЕЗМӘТЛӘР КҮРСӘТҮ БУЕНЧА ЭШКУАРЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРА БАШЛАУ ТУРЫНДА БЕЛДЕРҮЛӘР КАБУЛ ИТҮ ҺӘМ ИСӘПКӘ АЛУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ БУЛГАН ҺӘМ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮНЕ ТИКШЕРҮДӘ ТОТУЧЫ ОРГАННАРНЫҢ ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫҢ РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| ТР ДТИ җитәкчесе | 236-91-44 | Sergey.Kraynov@tatar.ru |
| ТР ДТИ җитәкчесе урынбасары | 236-81-11 | Irek.Shaydullin@tatar.ru |
| Торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлеге башлыгы | 236-94-45 | Marsel.Nisamutdinov@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт бүлеге җитәкчесе | 264-76-02 | Fail.Salihov@tatar.ru». |